**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары (муниципаль тур, 2025-2026 уку елы) 7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 150 минут**
**Максималь балл – 40**

## I. Тест биремнәре (15 балл).

1. Бер яки берничә вакыйганы үз эченә алган, кеше характерының бер сыйфаты, ягы, аның үсү-үзгәрүе хакында сөйләүче эпик жанр (2 балл):

Җавап: ___________________________________

2. Эчке композициягә карый (1 балл):
1) пейзаж, портрет, лирик чигенеш, диалог, монолог
2) әдәби әсәрнең бүлекләргә, бүлекчәләргә, строфаларга һ.б. бүленеше
3) вакыйгаларның билгеле бер эзлеклелектә үсеше

3. Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» әсәренең жанр формасы (2 балл):

Җавап: ___________________________________

4. Татар халык авыз иҗатының лиро-эпик жанры, фаҗигале, гыйбрәтле, гадәттән тыш хәлләр уңае белән язылган, нигезенә кайгылы яки көлкеле вакыйга салынган әсәр (1 балл):
1) җыр
2) дастан
3) бәет

5. Сюжетны хәрәкәткә китерә (1 балл):
1) конфликт
2) экспозиция
3) төенләнеш

6. Авторның сюжеттан тыш лирик, фәлсәфи, автобиографик һ.б. характердагы сүзләре, уйланулары (2 балл):

Җавап: ___________________________________

7. Кәеф, халәт, тойгы, кичереш һәм аларның үзгәрүен югалырга әзер мизгел кебек күрсәтүче, тышкы сурәт, кыяфәт, күренешне төсләр, тавышлар гармониясе ярдәмендә тергезүче модернистик агым (1 балл):
1) экспрессионизм

2) модернизм
3) импрессионизм

8. Төп герой тормышындагы берничә охшаш яки каршылыклы хәл, вакыйгалар тезмәсе сурәтләнгән, берничә сюжет сызыгы бер үзәк тирәсенә берләшкән эпик жанр (2 балл):

Җавап: ___________________________________

9. Рөстәм Галиуллинның «Сәлам...» әсәренең жанры (1 балл):
1) нәсер
2) хикәя
3) повесть

10. *Бүген беренче октябрь. Без, аркага капчыкларыбызны асып, кемнеңдер теләге буенча укырга килдек. Үгезләрдән, дегет, камыл исеннән, күксел урманнардан, зәңгәр төтенле, көйгән бәрәңге исе килеп торган басулардан безне кем аерды? Ник аердылар? Моны беребез дә белми иде.*

*Җәй буе борчак, яңа бәрәңге, әвендә киптерелгән, төтен тәме сеңгән яңа арыш умачы ашап, капчык күтәреп тән ныгып беткән – бүген әнә шул көчне кая куярга белгән юк…* Әлеге өзек кайсы авторның нинди әсәреннән алынган? (2 балл):

Җавап:_______________________________________

## II. Язма җавапка бәйле биремнәр (25 балл).

1. Теоретик төшенчә буларак сюжет һәм сюжет элементлары. Ибраһим Газиның «Ак сирень» хикәясендә сюжет элементларын табып языгыз (10 балл).

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

2. Ибраһим Газиның «Ак сирень» хикәясендә ак сирень образының мәгънәсен ачыклагыз. Көчле позициягә чыгарылган әлеге образ әсәрдә нинди функция үти дип уйлыйсыз? (5 балл):

3. Ибраһим Газиның «Ак сирень» хикәясендәге үзегез теләгән бер геройга характеристика бирегез (5 балл):

4. Ибраһим Газиның «Ак сирень» хикәясендә автор фикерен – идеяне билгеләгез. Ул нинди каршылык аша ачылып китә? (5 балл):